# Синоним һәм антоним сыйфатлар.

6 нчы сыйныф.

**- Исәнме, дустым! ( кулларын бирешәләр)**

**- Хәлләрең ничек? ( куларын иңсәгә куялар)**

**- Син кайда булдың? ( колакларын тоталар)**

**- Мин сагындым! ( кулны йөрәккә кую)**

**- Син килдеңме? ( кулларны якка җәяләр)**

**- Мин бик шат! ( кочаклашалар)**

- Бирем. Игътибар белән мәкальләрне һәм табышмакларны укыйк әле. Сыйфатларны табып ачыклыйк. Нинди сыйфатлар табарсыз?

- Аяксыз , кулсыз, үзе агачтан сикереп төшә.
- Ак җир, кара тап, нәрсә булыр, уйлап тап.
- Вөҗданы пакъ- йөзе ак.
- Теле озынның акылы кыска.

Аяксыз-кулсыз
ак-кара
озын-кыска
пакъ-ак

Дәреснең темасы :

Синоним һәм антоним сыйфатлар.

*Егерме сигезенче гыйнвар.*

*Сыйныф эше.*

*Синоним һәм антоним сыйфатлар.*

# Сыйфатлар.

Синоним сыйфатлар

Антоним сыйфатлар

- Мәгънә төсмерләре үзгә булса да, бер үк төрле билгене берничә сыйфат белән белдереп була. Андый сыйфатларны мәгънәдәш ягъни **синоним сыйфатлар** дип атыйлар. ( Олы, зур, дәү; начар, яман, әшәке)

- **Антоним сыйфатлар** – мәгънәләре буенча предметның бер - берсенә каршы билгеләрен белдерә торган сүзләр. ( Чиста-пычрак, бай-ярлы, юеш – коры)

**Бирем.** Антоним сыйфатлар өстәп , җөмләләрне әйтеп бетерегез.

Шикәр ак, ә күмер....





Кышын көн кыска, ә төн ......





Таш авыр, ә шар .....





Китап калын, ә дәфтәр.........






Алма баллы,




ә лимон.......




Кар йомшак,



ә боз.........



- **“ Парын тап” уены.** Синоним сыйфатларның парларын табарга.

Акыллы
Татлы
Баллы
Кечкенә
Бәләкәй
Күренекле
Атаклы
Салкын
Матур
Күркәм
Суык
Зирәк

149 нчы бит, 192 нче күнегү.

**Бирем**. Синоним сыйфатларның мәгънәләрен ачыклагыз. Аларны файдаланып, җөмләләр төзеп укыгыз.

1) матур, чибәр, сылу, гүзәл, зифа; 2) кыен, читен;
3) олы, өлкән, зур; 4) юка, нәзек, нечкә.

- Антоним һәм синоним сыйфатлар турынданиләр белдек?

- Ничек белдек? Дәрестә нәрсә эшләдек?

- Өй эше: 139 нчы күнегү.Сыйфатларның антоним парларын табып сызык аша языгыз.
- Иҗади эш. Синоним һәм антоним сыйфатларны кертеп, дустыңа характеристика язу.

**Рәхмәт миңа!**
**Рәхмәт сиңа!**
**Рәхмәт сезгә!**
**Рәхмәт безгә!**
**Рәхмәт барчабызга!**

Дәрес тәмам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.